Татарстан Республикасы исеменнән

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**КАРАРЫ**

**гражданнар О.Н. Меркурьева, А.И. Владимирова, С.К. Невирович һәм Л.В. Рагимова шикаятьләренә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясындагы 8, 11 һәм 13 пунктларының һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 18 ноябрендәге 9838 номерлы карары (2016 елның 6 июлендәге редакциясендә) белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә даими яшәүче күпбалалы гаиләләргә индивидуаль торак төзү өчен бушлай бирелүче җир кишәрлекләре исемлегенең тугызынчы һәм унынчы абзацларының конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

Казан шәһәре 2017 елның 26 декабре

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясындагы 8, 11 һәм 13 пунктларының һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 18 ноябрендәге 9838 номерлы карары (2016 елның 6 июлендәге редакциясендә) белән

располанган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә даими яшәүче күпбалалы гаиләләргә индивидуаль торак төзү өчен бушлай бирелүче җир кишәрлекләре исемлегенең тугызынчы һәм унынчы абзацларының конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданнар О.Н. Меркурьева, А.И. Владимирова, С.К. Невирович һәм Л.В. Рагимова шикаятьләре сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан дәгъва белдерелә торган норматив нигезләмәләрнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Шикаятьләр бер үк предметка кагылышлы булганга күрә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 50 статьясындагы икенче өлешенә таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды әлеге шикаятьләр буенча эшләрне бер башкаруга берләштерде.

Докладчы судья Л.В. Кузьмина мәгълүматын, яклар — гражданнар О.Н. Меркурьева һәм Л.В. Рагимова, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актларны чыгарган органнар вәкилләре — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсенең граждан законнары бүлеге мөдире И.И. Фәттахов, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре комитеты хокукый тәэмин итү бүлеге баш белгече Е.Н. Ситдыйкова, суд утырышына дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле үтенечнамәсе буенча чакырылган белгеч — Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре комитеты җир кишәрлекләренә хокукларны рәсмиләштерүгә аналитик ярдәм һәм социаль мәсьәләләр бүлеге башлыгы А.Р. Сафина аңлатмаларын, суд утырышына чакырылган: Татарстан Республикасы Президенты вәкиле — Татарстан Республикасы Президенты Дәүләт-хокук идарәсенең закон проектлары эшләү бүлеге баш киңәшчесе Р.В. Сидаков, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының вәкаләтле вәкиле — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының

Хокук идарәсе башлыгы М.Б. Сөнгатуллин, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — Татарстан Республикасы Хөкүмәте вәкиле — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы А.Б. Гревцов, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Югары суды судьясы М.М. Сафина, Татарстан Республикасы Арбитраж суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Арбитраж судының суд практикасын анализлау һәм гомумиләштерү бүлеге башлыгы Р.Р. Шкаликов, Татарстан Республикасы Прокуроры вәкиле — Татарстан Республикасы прокуратурасы Федераль законнар үтәлешенә күзәтчелек итү идарәсенең норматив хокукый актларның законлылыгына күзәтчелек итү бүлеге башлыгы А.Р. Вәлиәхмәтов, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән — Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппараты гражданнар хокукларын торгызу мәсьәләләре бүлегенең әйдәүче консультанты Р.Р. Мингалиев чыгышларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданнар О.Н. Меркурьева, А.И. Владимирова, С.К. Невирович һәм Л.В. Рагимова Татарстан Республикасы Җир кодексының (алга таба шулай ук — Кодекс) 32.1 статьясындагы 8, 11 һәм 13 пунктлары һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 18 ноябрендәге 9838 номерлы карары (2016 елның 6 июлендәге редакциясендә) белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә даими яшәүче күпбалалы гаиләләргә индивидуаль торак төзү өчен бушлай бирелүче җир кишәрлекләре исемлегенең (алга таба шулай ук — Исемлек) тугызынчы һәм унынчы абзацлары белән үзләренең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаятьләр белән мөрәҗәгать иттеләр.

Кодексның 32.1 статьясындагы 8 пунктында билгеләнгәнчә, өч һәм аннан күбрәк баласы булган, Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче гражданнарга индивидуаль торак төзелешен, дача төзелешен гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару (йорт янындагы җир кишәрлеге), бакчачылык, яшелчәчелек белән шөгыльләнү өчен бирүгә билгеләнгән җир кишәрлекләре исемлекләре Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестры белешмәләре нигезендә, әлеге җир кишәрлекләрен алу хокукы булган гражданнар исемлекләреннән чыгып билгеләнә торган ихтыяҗны исәпкә алып, Татарстан Республикасында муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан төзелә. Җир кишәрлекләре исемлекләре аларның бирелү максатлары нигезендә җирле үзидарә органнары тарафыннан һәркайсына аерым төзелә һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

Әлеге Кодексның 32.1 статьясындагы 11 пункты күздә тотканча, өч һәм аннан күбрәк баласы булган, Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче гражданнардан гариза кергән көннән башлап 30 көн эчендә җирле үзидарәнең вәкаләтле органы мөрәҗәгать итүчене индивидуаль торак төзелешен, дача төзелешен гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару (йорт янындагы җир кишәрлеге), бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү өчен җир кишәрлеге алу хокукы булган гражданнар исемлекләренә кертү турында карар кабул итә һәм мөрәҗәгать итүчегә уникаль исәпкә алу номеры бирә. Исемлекләр булдыруны һәм алып баруны җирле үзидарә органы җир кишәрлекләренең бирелү максатлары нигезендә һәркайсы буенча аерым гамәлгә ашыра. Гражданнарның чираты гариза бирелү көне һәм вакыты буенча билгеләнә. Гражданнарның уникаль исәпкә алу номерлары исемлекләре, чиратлылык күрсәтелеп, «Интернет» челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында урнаштырыла һәм гражданнарны исемлекләргә керткән саен һәм аларга җир кишәрлекләре бирелгән саен яңартылырга тиеш.

Югарыда күрсәтелгән Кодексның 32.1 статьясындагы 13 пункты билгеләгәнчә, индивидуаль торак төзелешен, дача төзелешен гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару (йорт янындагы җир кишәрлеге), бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү өчен гражданнарга җир кишәрлекләре бирү аларны исемлекләргә керткән көннән алып бер елдан да соңга калмыйча чиратлылык тәртибендә гамәлгә ашырыла. Җирле үзидарә органнары җир кишәрлекләрен сайлап алу процедурасын уздыру урынын, көнен һәм вакытын билгелиләр һәм гражданнарны чиратлылык һәм табылган җир кишәрлекләре саны нигезендә әлеге процедурада катнашу өчен билгелиләр. Җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнгән гражданнарга җир кишәрлеген сайлап алу процедурасы уздырыла торган көнгә кадәр 14 көннән дә соңга калмыйча аны уздыру урыны, датасы, вакыты турында адресатка тапшырылуы хакында белдерү кәгазе булган заказлы хат, телеграмма яисә, имза куйдырып, хәбәрнамә тапшыру юлы белән хәбәр ителә. Җир кишәрлекләре исемлегеннән гражданнар тарафыннан җир кишәрлеген сайлап алу чиратлылык нигезендә гамәлгә ашырыла, һәм бу хакта акт төзелә, ул мөрәҗәгать итүче һәм җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан имзалана.

Исемлекнең тугызынчы һәм унынчы абзацлары белән Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә даими яшәүче күпбалалы гаиләләргә индивидуаль торак төзү өчен бушлай бирелүче җир кишәрлекләре билгеләнгән, атап әйткәндә: Казан шәһәренең Совет районындагы Константиновка торак массивыннан төньяк-көнбатыштарак урнашкан, биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга бирү өчен билгеләнгән территория һәм Казан шәһәренең Авиатөзелеш районындагы Зур Дербышки һәм Щербаково торак массивлары арасында урнашкан, дүрт һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга бирү өчен билгеләнгән территория.

Шикаятьләрдән һәм аларга кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданнар О.Н. Меркурьева, А.И. Владимирова, С.К. Невирович һәм Л.В. Рагимова — өч баласы булган

күпбалалы аналар. Мөрәҗәгать итүчеләр 2013—2014 елларда индивидуаль торак төзелешен гамәлгә ашыру өчен аларны исемлекләргә керткән көннән алып бер елдан да соңга калмыйча бирелергә тиешле җир кишәрлеген түләүсез алуга хокуклары булган гражданнар исемлегенә кертелгән булганнар. Ләкин, алар күрсәткәнчә, Казан шәһәрендә өч баласы гына булган гаиләләргә җир кишәрлекләре фактта бирелми, чөнки, алар фикеренчә, дәгъвалана торган Исемлектә күпбалалы гаиләдәге бала санына карап, җир кишәрлекләрен бирүдә төрле алым кулланыла. Шулай, Казан шәһәреннән читтә урнашкан җир кишәрлекләре (Исемлекнең беренче—сигезенче абзацлары) бөтен күпбалалы гаиләләр өчен каралган, ә Казан шәһәре чикләрендәге җир кишәрлекләре бары тик биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаиләләр (Исемлекнең тугызынчы абзацы) һәм дүрт һәм аннан да күбрәк баласы булган гаиләләр (Исемлекнең унынчы абзацы) өчен каралган.

Гражданнар О.Н. Меркурьева, А.И. Владимирова, С.К. Невирович һәм Л.В. Рагимова күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлекләрен гариза бирелү көне һәм вакыты буенча чиратлылык тәртибендә бирү шарты Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясында инде билгеләнгән һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан күпбалалы гаиләдәге бала саныннан чыгып үзгәртелә алмый дип саныйлар. Ләкин, алар билгеләгәнчә, Исемлекнең дәгъвалана торган тугызынчы һәм унынчы абзацларында күпбалалы гаиләләргә конкрет җир кишәрлекләре күпбалалы гаиләдәге бала санынна чыгып бирелә дигән өстәмә шартлар билгеләүче норматив нигезләмәләр бар, бу исә юридик тигезлек һәм хокук өстенлеге конституциячел принципларына каршы килә.

Шул ук вакытта мөрәҗәгать итүчеләр күрсәтелгән Кодексның 32.1 статьясындагы 8 пункты җирле үзидарә органнарына җир кишәрлекләренең тиешле исемлекләрен булдыру вәкаләтен биреп, алар тарафыннан бары тик территорияләрне билгели торган һәм нинди дә булса гомуми кагыйдәләрсез һәм конкретлаштыручы норматив күрсәтмәләрсез норматив булмаган хокукый актлар кабул итүне күздә тота дип саныйлар.

Алар фикеренчә, әлеге Кодексның 32.1 статьясындагы 8, 11 һәм 13 пунктлары җирле үзидарә органнарының җир кишәрлекләре исемлекләрен булдырганда күпбалалы гаиләләрнең конкрет җир кишәрлекләренең урнашу урынын сайлавын андый гаиләләрдәге бала саны белән бәйләргә хокуклы түгел икәнлеген тулы ачыклык белән билгеләмиләр.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар О.Н. Меркурьева, А.И. Владимирова, С.К. Невирович һәм Л.В. Рагимова Татарстан Республикасы Конституция судыннан Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясындагы 8, 11 һәм 13 пунктларын һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 18 ноябрендәге 9838 номерлы карары (2016 елның 6 июлендәге редакциясендә) белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә даими яшәүче күпбалалы гаиләләргә индивидуаль торак төзү өчен бушлай бирелүче җир кишәрлекләре исемлегенең тугызынчы һәм унынчы абзацларын Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче һәм икенче өлешләр), 38 (беренче һәм өченче өлешләр), 55 һәм 58 статьяларына туры килми дип тануны сорыйлар, алар нигезендә закон һәм суд каршында һәркем тигез; дәүләт кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген социаль хәленә, яшәү урынына һәм башка шартларга бәйсез рәвештә гарантияли; гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен чикләүнең теләсә кайсы рәвеше тыела; Татарстан Республикасында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен дәүләт тарафыннан яклауның тигез хокукы гарантияләнә; гаилә, ана булу, ата булу һәм балачак дәүләт яклавында; дәүләт гаилә турында кайгырта; һәркем торакка хокуклы, беркем дә торагыннан нигезсез рәвештә мәхрүм ителә алмый; дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары торак төзелешен хуплыйлар, торакка хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыралар; Татарстан Республикасы Конституциясендә төп хокукларны һәм ирекләрне санап чыгу кешенең һәм гражданның гомумтанылган башка хокукларын һәм ирекләрен кире кагу һәм киметү буларак аңлатылмаска

тиеш; Татарстан Республикасында кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен юкка чыгара яисә киметә торган законнар чыгарылмаска тиеш.

«Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 18 ноябрендәге 9838 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2017 елның 21 декабрендәге 5323 номерлы карары белән Исемлекнең дәгъвалана торган нигезләмәләреннән күпбалалы гаиләләргә күрсәтелгән җир кишәрлекләре күпбалалы гаиләдәге бала саныннан чыгып бирелә дигән өстәмә шартлар юкка чыгарылган.

Әмма бу хәл үзеннән-үзе Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан мөрәҗәгать итүчеләр дәгъва белдерә торган нигезләмәләрнең конституциячеллеген тикшерүгә киртә була алмый, чөнки «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы икенче өлеше нигезендә конституциячеллеге дәгъваланучы акт юкка чыгарылган булса яисә эшне карый башлаганчы я аны карау чорында үз көчен югалткан булса, Татарстан Республикасы Конституция суды башлаган эш туктатылырга мөмкин, моңа бу актның гамәлдә булуы аркасында гражданнарның конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылган очраклар керми.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану практикасындагы мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән актның конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карарлар кабул итә һәм карар кабул иткәндә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясындагы 8, 11 һәм 13 пунктлары алар нигезендә гамәлдәге хокукый җайга салу системасында җирле үзидарә органнары тарафыннан күпбалалы гаиләләргә конкрет җир кишәрлекләрен түләүсез бирүнең өстәмә шартлары билгеләнүгә юл куела торган дәрәҗәдә, шулай ук Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 18 ноябрендәге 9838 номерлы карары (2016 елның 6 июлендәге редакциясендә) белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә даими яшәүче күпбалалы гаиләләргә индивидуаль торак төзү өчен бушлай бирелүче җир кишәрлекләре исемлегенең күпбалалы гаиләләргә конкрет җир кишәрлекләре күпбалалы гаиләдәге бала санынннан чыгып бирелә дигән өстәмә шартлар булган тугызынчы һәм унынчы абзацлары әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып торалар.

2. Мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан дәгъва белдерелә торган хокукый нигезләмәләр социаль яклау һәм җир законнары өлкәләренә кагыла. Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясы (1 өлешнең «ж» һәм «к» пунктлары) нигезендә социаль тәэминатны да кертеп, социаль яклау, шулай ук җир законнары Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагында. Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясында каралганча, Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектларының шулар нигезендә кабул ителә торган законнары һәм башка норматив хокукый актлары чыгарыла (2 өлеш); Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары Россия Федерациясе карамагындагы мәсьәләләр буенча, шулай ук Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча кабул ителгән федераль законнарга каршы килә алмый (5 өлеш).

Җир законнары Россия Федерациясе Җир кодексыннан, федераль законнардан һәм аларга ярашлы кабул ителә торган Россия Федерациясе субъектлары законнарыннан тора (Россия Федерациясе Җир кодексының 2 статьясындагы 1 пунктының беренче абзацы). Әлеге Кодексның 39.5 статьясындагы 6 пунктчасы белән дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеге өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнар милкенә вәкаләтле органның карары нигезендә Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары билгеләгән очракта һәм тәртиптә түләүсез бирелә дип билгеләнгән. Шул ук вакытта әлеге Кодекс, федераль законнар, Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары нигезендә һәм шуларны үтәү йөзеннән җирле үзидарә органнары үз вәкаләтләре чикләрендә җир хокукы нормаларын үз эченә алган актлар чыгара ала (2 статьяның 4 пункты).

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы беренче өлешенең 3 пункты белән шәһәр округының җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә шәһәр округының муниципаль милкендәге мөлкәтен биләү, аннан файдалану һәм аның белән эш итү кертелгән.

Эчтәлеге буенча тиңдәш нормалар Татарстан Республикасы Җир кодексының 5 статьясындагы 2 пунктчасы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясындагы беренче өлешенең 3 пункты һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының 2005 елның 17 декабрендәге 3-5 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 8 статьясындагы беренче өлешенең 3 пункты белән беркетелгән.

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясындагы беренче өлеше, Казан шәһәре

муниципаль берәмлеге Уставының 38 статьясындагы беренче өлеше белән үзара бәйләнештә 40 статьясындагы икенче өлешенең 4 абзацы буенча Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты муниципаль милек белән идарә итү өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне, шул исәптән җирле үзидарә органнарының җир мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтләренә Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Җир кодексы, башка федераль законнар, шулай ук Татарстан Республикасы законнары белән кертелгән мәсьәләләрне хәл итү йөкләнгән Казан шәһәре җирле үзидарәсенең башкарма-күрсәтмә органы булып тора.

Шулай итеп, дәгъвалана торган норматив хокукый актларны кабул итеп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты федераль һәм республика законнары нигезендә үзләренә бирелгән вәкаләтләрен законлы рәвештә гамәлгә ашырганнар, әлеге вәкаләтләр Татарстан Республикасы Конституциясенең үзара бәйләнештәге 75 (2 пункт) һәм 116 (беренче өлеш) статьяларына нигезләнгән, алар буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карамагына Татарстан Республикасы карамагындагы мәсьәләләрне һәм Россия Федерациясе һәм аның субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләрне Татарстан Республикасы вәкаләтләре чикләрендә закон чыгарып җайга салу керә; җирле үзидарә, закон нигезендә һәм үзенә җаваплылык алып, җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне халыкның мөстәкыйль хәл итүен, муниципаль милек биләүне, аннан файдалануны һәм аның белән эш итүне тәэмин итә.

3. Татарстан Республикасын социаль дәүләт дип игълан итеп (13 статья), Татарстан Республикасы Конституциясе шуны беркетә: гаилә, ана булу һәм балачак дәүләт яклавында, дәүләт гаилә турында кайгырта (38 статья, беренче һәм өченче өлешләр); һәркемгә шул исәптән балаларны тәрбияләү өчен һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә (54 статья, беренче өлеш); җир һәм башка табигать ресурслары хосусый, дәүләти, муниципаль милектә һәм милекнең башка рәвешләрендә

булырга мөмкин (18 статья, икенче өлеш). Мәгънәләре буенча тиңдәш гарантияләр Россия Федерациясе Конституциясе, шул исәптән аның 7, 9 (2 өлеш), 36 (1 өлеш), 38 (1 өлеш) һәм 39 (1 өлеш) статьялары белән билгеләнгән.

Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе кебек үк, җир кишәрлекләрен түләүсез бирүгә хокукны гарантияләми. Җир законнарының төп принципларын билгеләп, Россия Федерациясе Җир кодексы шул исәптән җирдән файдалануның түләүлелеге принцибын бүлеп чыгара, аның буенча, федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектлары законнары билгеләгән очраклардан тыш, җирдән теләсә нинди файдалану түләүле башкарыла (1 статьяның 1 пунктындагы 7 пунктчасы).

Шул ук вакытта Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясе буенча гаиләгә, ана һәм ата булуга, балачакка дәүләт ярдәмен тормышка ашыруның конкрет юнәлешләрен һәм чараларын билгеләү дискрециясенә ия булган закон чыгаручы, аерым алганда, шундый ярдәмне оештыру максатында дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан индивидуаль торак төзелешенә ярдәм итү мөмкинлекләрен шул исәптән моның өчен гражданнарның аерым категорияләренә җир кишәрлекләрен милек итеп түләүсез бирү һәм шуның белән торакка хокукны гамәлгә ашыруның өстәмә шартларын булдыру юлы белән кулланырга хокуклы (2017 елның 9 ноябрендәге 2516-О номерлы Билгеләмә).

3.1. Россия Федерациясе Җир кодексының 39.5 статьясы нигезендә дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген бирү очраклары арасында җир кишәрлеген өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнар милкенә Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары билгеләгән очракта һәм тәртиптә түләүсез бирү каралган (6 пунктча).

Татарстан Республикасында күрсәтелгән хокукый җайга салу Татарстан Республикасы Җир кодексында чагылыш тапкан, анда, үзенең дискрецион вәкаләтләре чикләрендә эш итеп, закон чыгаручы җир кишәрлекләрен өч һәм аннан күбрәк баласы булган, Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче гражданнар милкенә шул исәптән индивидуаль торак төзелешен гамәлгә ашыру өчен түләүсез бирү хокукын беркеткән (32 статьяның 3 пункты). Шул ук вакытта, андый хокукны тормышка ашыру механизмын билгеләп, республика закон чыгаручысы Россия Федерациясе Региональ үсеш министрлыгының 2013 елның 9 сентябрендәге 372 номерлы боерыгы белән расланган Өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләрен түләүсез бирү тәртибе һәм очраклары буенча Россия Федерациясе субъектларына методик тәкъдимнәр (алга таба шулай ук — Методик тәкъдимнәр) нигезләмәләрен дә игътибарга алган, алар буенча Россия Федерациясе субъектларының өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләрен түләүсез бирү очракларын һәм тәртибен билгели торган законнарында шул исәптән җирле үзидарә органнарының муниципаль берәмлек территориясендә өч һәм аннан күбрәк баласы булган шундый гражданнарга бирү өчен каралган җир кишәрлекләренең адреслы исемлеген алып бару буенча вәкаләтен билгеләргә тәкъдим ителә (21 пунктның 5 пунктчасы).

Шулай, Кодексның 32.1 статьясындагы дәгъвалана торган нигезләмәләре белән өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләрен түләүсез бирү тәртибе, аерым алганда, әлеге җир кишәрлекләрен алу хокукы булган гражданнар исемлекләреннән чыгып билгеләнә торган ихтыяҗны исәпкә алып, җирле үзидарә органнары тарафыннан җир кишәрлекләре исемлеген булдыру тәртибе (8 пункт); җир кишәрлекләренең бирелү максатлары нигезендә җирле үзидарә органы тарафыннан һәркайсы буенча аерым шундый исемлекләр булдыру һәм алып бару һәм гражданнарның чиратын гариза бирелү көне һәм вакыты буенча билгеләү тәртибе (11 пункт); гражданнарга җир кишәрлекләрен бирү срогы

һәм җир кишәрлекләрен сайлап алу процедурасын уздыру тәртибе (13 пункт) билгеләнгән.

Дәгъвалана торган нигезләмәләрнең сүзгә-сүз эчтәлегеннән аңлашылганча, алар өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарның җир кишәрлеген түләүсез алу хокукын гамәлгә ашыруга юнәлгән законнарда билгеләнгән хокукый нормаларны үтәү буенча җирле үзидарә органнарының гамәлләре эзлеклелеген билгелиләр. Шул ук вакытта, шундый җир кишәрлекләрен бирү процедурасын билгеләү вәкаләтләрен җирле үзидарә органнарына йөкләп, республика закон чыгаручысы моның өчен мәҗбүри булган шартларны ачык һәм төгәл билгеләгән. Җир кишәрлекләре исемлеген булдыруга карата шундый шартларның берсе булып җир кишәрлекләренә ихтыяҗ тора, әлеге ихтыяҗ аларны алырга хокукы булган гражданнарның гариза бирелү көне һәм вакытына карап булдырыла торган исемлекләреннән чыгып билгеләнә.

Шуның белән Татарстан Республикасы Җир кодексының мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан дәгъвалана торган нормалары үзләренең мәгънәсе һәм эчтәлеге буенча өч һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чарасы күрсәтүнең оештыру-хокукый механизмын билгелиләр һәм аларның потенциаль аеруча киеренке социаль хәлдә торган һәм тигезлек һәм гаделлек конституциячел принциплары нигезендә дәүләт белән җәмгыятьнең аерым кайгыртуына мохтаҗ булган гаиләләр буларак җир кишәрлекләренә ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлгән. Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясындагы карала торган 8, 11 һәм 13 пунктлары системалы берлектә торалар, үзләренең максатчан билгеләнеше буенча өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләрен түләүсез бирү процедурасын җайга салуга юнәлгәннәр, шулай ук җирле үзидарә органнары өчен әлеге өлкәдә шул исәптән тиешле норматив хокукый актлар кабул итү буенча вәкаләтләрнең төгәл исемлеген күздә тоталар, бу үзеннән-үзе тиешле муниципаль берәмлек территориясендә конкрет җир кишәрлекләре бирүнең зуррак юридик көчкә ия булган актта

тулы рәвештә каралганнардан үзгә өстәмә шартларын җирле үзидарә органнары тарафыннан кертүне рөхсәт итми.

Шулай итеп, дәгъвалана торган закон нормалары хокук куллану практикасында аларның башка төрле аңлатылуына юл куймыйлар, кеше һәм гражданның конституциячел хокукларын, шул исәптән мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын юкка чыгармыйлар, киметмиләр һәм башкача бозмыйлар һәм, димәк, Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче һәм икенче өлешләр), 38 (беренче һәм өченче өлешләр), 55 һәм 58 статьяларына каршы килмиләр.

3.2. Россия Федерациясе Конституция Суды үз карарларында күрсәткәнчә, җирле үзидарәнең халыкка иң якын булган һәм шул исәптән муниципаль берәмлекләрдәге халыкның көнкүрешен турыдан-туры тәэмин итү белән бәйле социаль дәүләт бурычларын үтәүгә юнәлгән гавами хакимият буларак конституциячел табигате әлеге гавами хакимият үзенчәлекләрен исәпкә алу кирәклеген китереп чыгара; бу, бер яктан, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләре чикләрендә мөстәкыйльлеге һәм, икенче яктан, гражданнарга, аларның нинди муниципаль берәмлек территориясендә яшәүләренә карамастан, закон нигезендә алынган хокукларны кертеп, тиешле социаль хокукларны гарантияләү кебек конституциячел яклана торган кыйммәтләр балансын булдыру кирәклеген күздә тота (2003 елның 11 ноябрендәге 16-П номерлы, 2006 елның 15 маендагы 5-П номерлы, 2011 елның 18 маендагы 9-П номерлы, 2017 елның 5 июлендәге 18-П номерлы һ.б. карарлар).

Тикшерелә торган эшкә карата әлеге хокукый позиция шул исәптән җирле үзидарә органнарының өч һәм аннан күбрәк баласы булган, аерым муниципаль берәмлек территориясендә даими яшәүче күпбалалы гаиләләргә индивидуаль торак төзелешен гамәлгә ашыру өчен түләүсез бирелә торган җир кишәрлекләре исемлеген булдыру тәртибен регламентлаштыра торган актларының эчтәлеге һәм мәгънәсенә нигез булып тора.

Мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан китерелә торган дәлилләр шуны күрсәтәләр: үзләренең конституциячел хокукларының бозылуын алар турыдан-туры исемлекнең дәгъвалана торган тугызынчы һәм унынчы абзацлары текстында әлеге абзацларда каралган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе чикләрендә урнашкан конкрет җир кишәрлекләрен күпбалалы гаиләләрнең аерым категорияләренә бала санына карап (тиешенчә биш һәм аннан күбрәк, дүрт һәм аннан күбрәк) бирүнең өстәмә шартлары булу белән бәйлиләр, бу исә өч балалы күпбалалы гаиләләргә әлеге җир кишәрлекләрен алуга хокукларын тормышка ашыруга комачаулый.

Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позицияләрен кулланып, Татарстан Республикасы Конституция суды федераль законнарда да, республика законнарында да күпбалалы гаиләнең бердәй төшенчәсе күрсәтелми дип билгеләгән иде инде. Монда «гаилә» төшенчәсенең норматив эчтәлеге хокукый җайга салу максатларыннан чыгып төрле юридик эчтәлек белән баетыла (2011 елның 5 октябрендәге 44-П номерлы карар).

Тикшерелә торган хокукый мөнәсәбәтләр өлкәсенә карата Россия Федерациясе Җир кодексы белән дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләре өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары билгеләгән очракта һәм тәртиптә түләүсез бирелә дип турыдан-туры билгеләнгән (39.5 статьяның 6 пунктчасы). Бирелгән вәкаләтләр кысаларында республика закон чыгаручысы Татарстан Республикасы Җир кодексында өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнар буларак күпбалалы гаилә таныла дип билгеләгән (32 статьяның 3 пунктындагы дүртенче абзацы). Шул ук вакытта күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлекләрен бирү өчен хокукый шартлар буларак республика закон чыгаручысы бары тик аларның Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү фактын, шулай ук аларны исәпкә кую буенча чиратлылыкны хронологик принципта булдыруны билгеләгән.

Исемлекнең дәгъвалана торган нигезләмәләренә анализ Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты аларда күрсәтелгән җир кишәрлекләрен бары тик дүрт һәм аннан күбрәк, биш һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләргә генә бирүне билгеләгән дип күрсәтә. Үзенең хокукый мәгънәсе буенча аларның эчтәлеге фактта өстәмә шартлар билгели, алар нигезендә социаль ярдәмнең әлеге чарасы күрсәтелүгә хокукны турыдан-туры Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә күпбалалы гаиләләрнең бары тик аерым категорияләре генә тормышка ашырырга мөмкин.

Ләкин федераль һәм республика җир законнарының югарыда китерелгән нормалары нигезендә бөтен күпбалалы гаиләләр андый гаиләләрдәге бала санына да, шулай ук җир кишәрлекләренең урнашу урынына да бәйсез рәвештә җирне түләүсез алу мөмкинлегенә тигез рәвештә ия. Җирле үзидарә органнары, шул исәптән Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты күпбалалы гаиләләргә бирү өчен каралган җир кишәрлекләре исемлеген (урнашу урыны һәм мәйданы) генә билгели алалар, алар тиешле гаризаларны бирү чиратлылыгына гына бәйле рәвештә булдырылачак һәм бөтенесе арасында бүленәчәк. Татарстан Республикасында күпбалалы гаиләләрнең аерым категорияләре өчен өстенлекле хокук билгеләү дәүләт хакимияте органнарының аерым хокукы булып тора һәм җирле үзидарә органнары вәкаләтләре чикләреннән чыга. Моңа Методик тәкъдимнәрдә дә күрсәтелгән, аларның 8 пунктында турыдан-туры шул күздә тотылган: өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләрен бирү өчен шартлар, Россия Федерациясе субъектларындагы социаль-икътисади һәм демографик ситуациядән чыгып, Россия Федерациясе субъекты законнары белән шул исәптән дифференциацияләнгән рәвештә билгеләнергә мөмкин.

Димәк, җирле үзидарә органнары, халыкка иң якын булган гавами хакимият органнары буларак, тиешле хокукый җайга салуны гамәлгә ашырганда, шулай ук конкрет җир кишәрлекләрен билгеләгәндә дә формаль

яктан тигез субъектлар — өч һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр мөнәсәбәтендә законнарда билгеләнгән хокукны тормышка ашыруда тигез алымны тәэмин итәргә тиешләр.

Шуңа бәйле рәвештә Исемлекнең дәгъвалана торган абзацларында күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлекләре гаиләдәге бала санына карап бирелә дигән өстәмә шартлар булу закон өстенлеге, тигезлек һәм гаделлек, законга һәм дәүләт гамәлләренә гражданнарның ышанычын саклау принципларын боза, шулай ук өч баласы гына булган гражданнарга турыдан-туры Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җир кишәрлеген милеккә түләүсез тапшыру рәвешендә бирелгән дәүләт ярдәменә хокукның асылына кагыла.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Конституция суды шундый нәтиҗәгә килә: Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 18 ноябрендәге 9838 номерлы карары (2016 елның 6 июлендәге редакциясендә) белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә даими яшәүче күпбалалы гаиләләргә индивидуаль торак төзү өчен бушлай бирелүче җир кишәрлекләре исемлегенең күпбалалы гаиләләргә конкрет җир кишәрлекләре күпбалалы гаиләдәге бала саныннан чыгып бирелә дигән өстәмә шартлар булган тугызынчы һәм унынчы абзацлары Татарстан Республикасы Конституциясенең 10, 24 (беренче һәм икенче өлешләр), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче һәм икенче өлешләр), 38 (беренче һәм өченче өлешләр), 55, 58 һәм 116 (беренче өлеш) статьяларына туры килми.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6, 63 статьяларына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67, 68, 69, 71, 73 һәм 104 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясындагы 8, 11 һәм 13 пунктларын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

2. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 18 ноябрендәге 9838 номерлы карары (2016 елның 6 июлендәге редакциясендә) белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә даими яшәүче күпбалалы гаиләләргә индивидуаль торак төзү өчен бушлай бирелүче җир кишәрлекләре исемлегенең тугызынчы һәм унынчы абзацларын аларда күпбалалы гаиләләргә конкрет җир кишәрлекләре күпбалалы гаиләдәге бала санынннан чыгып бирелә дигән өстәмә шартлар билгеләнгән өлештә Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип танырга.

3. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

4. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 72 статьясы нигезендә бу Карар «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 77-П** **Татарстан Республикасы Конституция суды**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
КОНСТИТУЦИОННЫЙ СУД РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ИНН 1655039191
ОГРН 1021602845241